ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.08.2026 с.Старое Дрожжаное № 406

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Дуван башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркеме эшчәнлеген туктатып тору турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы Г.Ф. Хәлиулловның докладын исәпкә алып, мәктәпкәчә яштәге балалар булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Дуван башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә төркеме эшчәнлеген 2027 елның 1 сентябренә кадәр туктатырга.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Дуван башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече яштәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорына

2.1. Мәктәпкәчә төркем эшчәнлеген халыкка туктатып тору турында мәгълүмат җиткерергә;

2.2. Әлеге карар белән мәктәпкәчә мәгариф учреждениесенең барлык штаттагы хезмәткәрләрен үз вакытында таныштырырга;

2.3. Мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә инвентаризация үткәрүне тәэмин итәргә;

2.4. Җиһазларның саклануын тәэмин итәргә;

2.5. Гамәлдәге хезмәт законнары нигезендә эшләүне туктатып тору чорында мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе хезмәткәрләренең эшен оештырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы Г.Ф. Хәлиулловка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов